**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**

**КАРАР**

2016 ел, 26 декабрь № 989

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясенең Наркотиклар әйләнешен контрольдә тоту федераль хезмәтен һәм Федераль миграция хезмәтен бетерүгә бәйле рәвештә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2010 елга кадәр һәм 2030 елга кадәрге перспективага Татарстан Республикасын демографик үстерү комплекслы программасын раслау турында» 2009 ел, 12 гыйнвар, 6 нчы карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 ел, 12 ноябрь, 896 нчы, 2011 ел, 12 июль, 562 нче, 2011 ел, 5 декабрь, 995 нче, 2014 ел, 29 декабрь, 1054 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган 2010 елга кадәр һәм 2030 елга кадәрге перспективага Татарстан Республикасын демографик үстерү комплекслы программасына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

5 бүлектә:

5.1.1 таблицаның 5 юлында «Федераль миграция хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе» сүзләрен төшереп калдырырга;

5.1.2 таблицаның 5 юлында «Россия Федерациясе Федераль миграция хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе» сүзләрен төшереп калдырырга.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының дәүләт программалары исемлеген һәм Татарстан Республикасының дәүләт программаларын, ведомство максатчан программаларын эшләү, тормышка ашыру һәм нәтиҗәлелеген бәяләү тәртибен раслау турында» 2012 ел, 31 декабрь, 1199 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 ел, 26 апрель, 282 нче; 2013 ел, 29 апрель, 294 нче; 2013 ел, 29 июнь, 454 нче; 2013 ел, 19 июль, 507 нче; 2013 ел, 24 октябрь, 789 нчы; 2013 ел, 31 декабрь, 1110 нчы; 2014 ел, 15 март, 157 нче; 2014 ел, 14 апрель, 242 нче; 2014 ел, 11 июнь, 405 нче; 2014 ел, 9 июль, 475 нче; 2014 ел, 5 сентябрь, 644 нче; 2015 ел, 6 май, 326 нчы; 2015 ел, 16 май, 346 нчы; 2015 ел, 22 июль, 532 нче; 2016 ел, 17 февраль,

101 нче һәм 2016 ел, 27 апрель, 252 нче; 2016 ел, 12 май, 298 нче; 2016 ел, 10 июнь, 396 нчы; 2016 ел, 12 октябрь, 740 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасының дәүләт программалары исемлегенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

5 нче, 20 нче һәм 21 нче пунктларда «Федераль миграция хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе (килешү буенча)» сүзләрен төшереп калдырырга;

6 нчы пунктта «Россия Федерациясенең Наркотиклар әйләнешен контрольдә тоту федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе (килешү буенча)» сүзләрен төшереп калдырырга.

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2030 елга кадәр Татарстан Республикасын социаль-икътисадый үстерү стратегиясен гамәлгә ашыру буенча чаралар планын раслау турында» 2015 ел, 25 сентябрь, 707 нче карары белән расланган 2030 елга кадәр Татарстан Республикасын социаль-икътисадый үстерү стратегиясен гамәлгә ашыру буенча чаралар планына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

4 бүлекнең таблицасындагы 1.1.4 нче пунктта «Федераль миграция хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе (килешү буенча)» сүзләрен «Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы (килешү буенча)» сүзләренә алмаштырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры
вазыйфаларын башкаручы А.В.Песошин

F:\KARAR\2016\989.doc